**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2016 ел, 27 гыйнвар № 43

г. Казань

«Түбән Кама агросәнәгать көллияте» дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесен, аңарга «Сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән укучылар өчен 63 нче һөнәри училище» дәүләт бюджет һөнәри белем бирү учреждениесен кушу рәвешендә, үзгәртеп оештыру турында

Татарстан Республикасының һөнәри белем бирү оешмалары челтәрен оптимальләштерү, квалификацияле эшчеләр һәм урта буын белгечләре әзерләүнең сыйфатын күтәрү һәм хезмәт ресурсларын нәтиҗәлерәк файдалану максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының «Түбән Кама агросәнәгать көллияте» дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесен (алга таба – Түбән Кама агросәнәгать көллияте), аңарга «Сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән укучылар өчен 63 нче һөнәри училище» дәүләт бюджет һөнәри белем бирү учреждениесен (алга таба – 63 нче һөнәри училище) кушу рәвешендә, Түбән Кама агросәнәгать көллияте эшчәнлегенең төп максатларын саклап, үзгәртеп оештыру турында тәкъдимен кабул итәргә.

2. Дәүләт хезмәтләре күрсәтүгә (эшләр башкаруга) дәүләт йөкләмәсен үтәү өчен финанслар белән тәэмин итү Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләренә карата дәүләт йөкләмәсен формалаштыру һәм аның үтәлешен финанслар белән тәэмин итү тәртибе турында» 2010 ел, 29 апрель, 308 нче карарында билгеләнгән тәртиптә, күрсәтелгән максатларга тиешле финанс елына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законында каралган акча кысаларында гамәлгә ашырыла дип билгеләргә.

3. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына:

Түбән Кама агросәнәгать көллиятен гамәлгә куючы вазыйфаларын һәм вәкаләтләрен башкарырга;

Түбән Кама агросәнәгать көллиятен үзгәртеп оештыру белән бәйле законнарда каралган чараларны үткәрүне тәэмин итәргә;

«Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон һәм «Мәгариф турында» 2013 елның 22 июлендәге 68-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы таләпләрен саклап, 63 нче һөнәри училищеда укучыларны ата-аналары (законлы вәкилләре) ризалыгы белән, укыту шартларын һәм программаларын саклап, 2016 елның 1 сентябреннән Түбән Кама агросәнәгать көллиятенә күчерүне тәэмин итәргә;

үзгәртеп оештыру чаралары нәтиҗәсендә эштән азат ителә торган хезмәткәрләргә гарантияләр һәм компенсацияләр бирүне законнар нигезендә тәэмин итәргә;

бер ай эчендә түбәндәгеләргә тиешле үзгәрешләрне кертергә:

Түбән Кама агросәнәгать көллияте уставына;

Түбән Кама агросәнәгать көллияте өчен дәүләт хезмәтләре күрсәтүгә (эшләре башкаруга) дәүләт йөкләмәсенә;

Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына әлеге карарның 4 пунктын үтәү өчен кирәкле документларны, шул исәптән күчемсез милек объектларына техник документларны тапшырырга.

4. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына:

Түбән Кама агросәнәгать көллияте Уставына кертелгән үзгәрешләрне дәүләт теркәвенә алган көннән соң 30 көн эчендә 2016 елның 1 сентябреннән түбәндәгеләрне оператив идарә хокукында беркетергә:

Татарстан Республикасы, Түбән Кама шәһәре, Җиңүнең 30 еллыгы урамы, 7 а йорт адресы буенча урнашкан, элек 63 нче һөнәри училищега беркетелгән күчемсез милек объектларын «Түбән Каманың сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән балалар өчен 23 нче мәктәбе» дәүләт бюджет гомуми белем бирү учреждениесенә (алга таба – 23 нче Түбән Кама мәктәбе);

элек 63 нче һөнәри училищега беркетелгән күчмә дәүләт мөлкәтен Түбән Кама агросәнәгать көллиятенә;

Түбән Кама агросәнәгать көллияте Уставына кертелгән үзгәрешләрне дәүләт теркәвенә алган көннән соң 90 көн эчендә элек даими (вакыты чикләнмәгән) файдалану хокукында 63 нче һөнәри училищеныкы булган җир кишәрлеген даими (вакыты чикләнмәгән) файдалану хокукында 23 нче Түбән Кама мәктәбенә бирергә;

Түбән Кама агросәнәгать көллияте Уставына кертелгән үзгәрешләрне дәүләт теркәвенә алган көннән соң 120 көн эчендә элек 23 нче Түбән Кама мәктәбенә беркетелгән дәүләт мөлкәтен Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы тәкъдиме нигезендә Түбән Кама муниципаль районына беркетергә.

5. Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына «2016 елга Татарстан Республикасы бюджеты турында» 2015 елның 20 сентябрендәге 97-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына тиешле үзгәрешләрне кертергә.

6. «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Татарстан Республикасының Икътисадый һәм социаль тикшеренүләр үзәге» дәүләт бюджет учреждениесенә, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы белән берлектә, әлеге карарның 3 – 5 пунктлары үтәлгәннән соң бер ай эчендә Татарстан

Республикасы Министрлар Кабинетының «2016 елга урта звено белгечләрен әзерләү программаларын тормышка ашыруга норматив чыгымнарны һәм Татарстан Республикасының дәүләт һөнәри белем бирү оешмаларын торак урыннар белән тәэмин итүгә нормативлар чыгымнарны раслау турында» 2015 ел, 16 октябрь, 776 нчы, «2016 елга Татарстан Республикасы һөнәри белеме бирү оешмаларының квалификацияле эшчеләр, хезмәткәрләр әзерләү программаларын тормышка ашыруга норматив чыгымнарын раслау турында» 2015 ел, 30 октябрь, 820 нче, «2016 елга адаптацияләнгән төп гомуми белем бирү программалары буенча белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы Татарстан Республикасы карамагындагы оешмаларның һәм шифаханә белем бирү оешмаларының норматив чыгымнарын раслау турында» 2015 ел, 30 сентябрь, 728 нче карарларына, алары әлеге карарның 1, 4 нче пунктларына туры китерү өлешендә үзгәрешләр кертү хакында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары проектларын эшләргә һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына кертергә.

7. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2016\43.docx